Казанлылар үзләренең бөек якташлары турында истәлекләрен кадерләп саклый. Татарстан башкаласының элеккеге Оренбург урамы 1963 елдан Шаляпин исемен йөртә. А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее (2018 елда исемен үзгәрткәнче – А.М. Горький әдәби-мемориаль музее) 1973 елдан бирле «Шаляпин укулары» исемле Бөтенроссия фәнни конференцияләре үткәрә, аларда Мәскәү, Санкт-Петербург һәм башка шәһәрләрдән килгән галимнәр, югары уку йортлары укытучылары, музей хезмәткәрләре, коллекционерлар катнаша. 1982 елның февраленнән ел саен М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры сәхнәсендә Фёдор Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале үткәрелә. Казанга илнең барлык тарафларыннан танылган опера сәхнәсе йолдызлары килә, алар шулай ук Ф.Шаляпин репертуарында да булган опералларда катнашалар. 1999 елның 29 августында Казанның Бауман урамында, үзе сабый чакта чукындырылган Богоявленский соборы янында Ф.Шаляпинга һәйкәл (скульптор А. Балашов) ачыла.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Шаляпин Ф.И.** Маска и душа / [предисл. «Завет и исповедь» Б.А. Покровского]. – Москва: Вагриус, 1997. – 319 с., 16 л. ил.

**Коновалова С.** Казанга һәм дөньяга Ходай бүләге // Казан. – 2013. – № 3. – Б. 52–55.

**Хәеров А.** Шаляпинның Казандагы адреслары буйлап // Татарстан. – 2018. – № 2. – Б. 40–46.

**Баһаветдинова А.** Шаляпин һәм Казан // Фәнни Татарстан. – 2003. – № 1. – Б. 20–24.

**Фәйзрахманов Ә.** Шаляпин Арчада укыган // Шәһри Казан. – 2005. – 12 авг.

**Американ Казанга бага:** [Ф. Шаляпинның кызы әтисе турында] // Шәһри Казан. – 2000. – 18 авг.

**Зөлфәт.** Моңсарларны уяткан җир: шигырь // Шәһри Казан. – 1999. – 28 авг.

**Гольцман С.В.** Ф. И. Шаляпин в Казани. – 2-е изд., перераб. и доп. – Казань: Kazan-Казань, 2002. – 319 с.: фотоил., портр. + 1 л. карт. – (Казань и казанцы; История в событиях и лицах). – В прил. список адресов, связанных с жизнью и деятельностью Ф.И. Шаляпина в Казани. – Библиогр.: с. 309–313

**Казань в жизни и творчестве А.М. Горького и Ф.И. Шаляпина:** материалы науч. конференции, посвящ. 1000-летию Казани и 65-летию Литературно-мемориального музея А.М. Горького (23 марта 2005 г.), а также Шаляпинских чтений (13 февр. 2006 г.). – Казань: Школа, 2009. – 154 с.: ил.

**Шаляпинские** чтения в Литературно-мемориальном музее А.М. Горького в Казани (1992–2002). – Казань: Карпол, 2002. – 110 с.: фотоил.

**Шаляпинские чтения:** 1992 г. / редкол.: Г.М. Кантор (сост.) [и др.]. – Казань, 1995. – 78 с.

**Елизарова М.Н.** Незабываемые годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 168 с.

**Путеводитель** по экспозиции Литературно-мемориального музея А.М. Горького = А.М. Горький әдәби-мемориаль музее экспозициясе буенча юл күрсәткеч. – Казань, 2016. – 38 с.: ил. – На обл.: Писатель. Эпоха. Герой: «Жизненный и творческий путь А.М. Горького», «Ф.И. Шаляпин и Казань». – Текст парал. рус., татар. яз.

**Вавиличева И.** Фёдор Шаляпин: «Моя мечта неразрывно связана с Россией»: [внук И.Ф. Шаляпина Иван де Лимюр передал в Казань уникальные документы из парижского дома великого певца] // Казань. – 2020. – № 4. – С. 56–67.

**Хаиров А.** По казанским адресам Шаляпина // Татарстан. – 2018. – № 2. – С. 66–71.

**Хайрутдинова Д., Гаврилова М.** «На память. Ф.Шаляпин»: [в музее им. М.Горкого хранятся фотографии с автографами Ф.И. Шаляпина // Казань. – 2018. – № 2. – С. 28–30.

**Гаврилова М.** Шаляпинские места в Казани // Казань. – 2017. – № 2. – С. 52–63.

**Фёдор Шаляпин:** [Кинофильм] / ТНВ Татарстан. – Казан: ТНВ Татарстан, 2009. – 1 электрон. опт. диск (DVD-ROM): зв., цв. + 1 бр. [23 б.]. – («Ватандашлар» циклы фильмнарының алтын коллекциясе; диск 48). – Татар телендә.

## 2 марта/март



## Дарджия АППАКОВА
## Дәрҗия АППАКОВА

**1898–1948**

**125 лет со дня рождения**
**туувына 125 ел**

Прозаик и драматург, внесшая вклад в развитие татарской советской детской литературы, Дарджия Сейфулловна (Дарья Семёновна) Аппакова родилась 2 марта 1898 года в деревне Байгулово Мензелинского уезда Уфимской губернии (ныне Нижнекамский район Республики Татарстан) в семье крестьянина-бедняка.

Тринадцатилетней девочкой приезжает в Казань, в 1914–1917 годах учится в учительской школе для крещёных татар. После её окончания несколько лет работает учительницей в Казани и родной деревне. В 1922–1923 годах учится в Советской партийной школе и в театральной студии при Казанском Большом драматическом театре. Некоторое время выступает в составе театральной группы при Казанском политотделе Запасной Армии Республики. В 1925–1928 годах работает инструктором Татарского обкома комсомола и сотрудником-организатором Бугульминского канткома РКП(б).

В 1928 году Д.Аппакова уезжает в Среднюю Азию, где до 1943 года работает учительницей в различных школах, организатором образовательно-просветительской работы среди женщин. В 1948 году она возвращается в Казань и до последних дней жизни продолжает творческую деятельность как профессиональный писатель.

Д.Аппакова пришла в литературу через журналистику. В двадцатые годы прошлого века в Казани выходила газета крещёных татар «Кызыл әләм» («Красное знамя») (впоследствии – «Кинәш»), на страницах которой были опубликованы многие ее статьи, очерки о преобразованиях на селе, женском движении.

Переехав в Ташкент, она вплотную занимается литературным творчеством. В 1932–1940 годы в Ташкенте на узбекском и русском языках увидели

свет рассказы и повести для детей и взрослых о прошлом и послереволюционной жизни народов разных национальностей: «Сәнәкчеләр» («Вилочники», 1932), «Яшь ударниклар» («Юные ударники», 1932), «Мәмәт һәм Аман карт» («Мамет и старик Аман», 1934), «Михнәт» («Михнат», роман в двух частях, 1934, 1935), «Кечкенә Бануның тарихы» («История маленький Бану», 1937) и трёхактная пьеса «Дошман» («Враг», 1939) для детского театра. Повесть «Кечкенә Бануның тарихы» («История маленький Бану») принесла ей известность и была переведена на русский, узбекский, английский языки.

В казанский период творчества (1943–1948 гг.) Д.Аппакова основное внимание уделяет детской драматургии. В эти годы были созданы её пьесы «Тапкыр егет» («Находчивый юноша, 1943), «Шүрәле» («Шурале», 1944), «Бишек жыры» («Колыбельная», 1946) «Илдус» («Ильдус», 1947). Написанная по мотивам татарского фольклора пьеса «Тапкыр егет» («Находчивый парень») в 1945–1946 и 1974–1975 годах была поставлена на сцене Татарского государственного академического театра имени Г. Камала. Пьеса также была переведена на русский язык и с успехом шла на сцене Казанского ТЮЗа.

Д. Аппакова трагически погибла 28 мая 1948 года.

Татар совет балалар әдәбиятын үстерүгә өлеш керткән прозаик һәм драматург Дәрҗия Сәйфулла кызы (Дарья Семёновна) Аппакова 1898 елның 2 мартында Уфа губернасының Минзәлә өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) Байгол авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Унөч яшендә Казанга килеп, 1914–1917 елларда, керәшен татарлары өчен ачылган укытучылар мәктәбендә укый. Аны тәмамлагач, берничә ел Казанда һәм туган авылында балалар укыта. 1922–1923 елларда Совет партия мәктәбендә һәм Казан Зур драма театры каршындагы театр студиясендә укый. Берникадәр вакыт Республика Запас армиясенең Казан сәясәт бүлеге каршындагы театр труппасы составында чыгыш ясый, 1925–1928 елларда комсомолның Татарстан өлкә комитеты инструкторы һәм РКП(б)ның Бөгелмә кантоны бүлегендә оештыручы-хезмәткәр булып эшли.

1928 елда Д.Аппакова Урта Азиягә күчеп китә һәм 1943 елга кадәр андагы төрле мәктәпләрдә укытучы, хатын-кызлар арасында мәгариф-агарту эшләрен оештыручы хезмәтендә була. 1943 елда Казанга кайтып, гомеренең соңгы көннәренәчә, профессиональ язучы буларак, иҗат эшчәнлеген дәвам иттерә.

Д.Аппакова әдәбиятка журналистика аша килеп керә. Егерменче елларда Казанда керәшен татарлары өчен чыга торган «Кызыл әләм» (соңыннан– «Киңәш») газетасы битләрендә аның авыл тормышындагы үзгәрешләр, хатын-кызлар хәрәкәте турында күп кенә мәкаләләре, очерклары басыла.

Ташкентка күчеп киткәч исә ул ныклап торып әдәби иҗат эшенә керешә. 1932–1940 еллар арасында Ташкентта үзбәк һәм рус телләрендә балалар һәм зурлар өчен язучының төрле милләт халыкларының үткәндәге һәм революциядән соңгы тормыш күренешләрен яктырткан «Сәнәкчеләр» (1932), «Яшь ударниклар» (1932), «Мәмәт һәм Аман карт» (1934), ике кисәктән торган «Михнәт» романы (1934, 1935), «Кечкенә Бануның тарихы» (1937) исемле хикәя, повестьлары һәм балалар театры өчен «Дошман» (1939) дигән өч пәрдәле пьесасы дөнья күрә. Болардан «Кечкенә Бануның тарихы» повесте аеруча ник танылa. Бу повесть тиз арада рус, татар, үзбәк һәм инглиз телләрендә басылып чыга.

Казан чорында (1943–1948 еллар) Д.Аппакова төп игътибарын балалар драматургиясенә юнәлтә. Бу елларда аның «Тапкыр егет» (1943), «Шүрәле» (1944), «Бишек жыры» (1946), «Илдус» (1947) исемле пьесалары иҗат ителә. Татар фольклоры мотивларына нигезләп язылган «Тапкыр егет» пьесасы 1945–1946 һәм 1974–1975 елларда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелып, тамашачыларның мәхәббәтен казана. Ул шулай ук, русчага тәрҗемә ителеп, Казанның Яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) сәхнәсендә дә уңыш белән бара.

Д. Аппакова 1948 елның 28 маенда фаҗигале рәвештә вафат була.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Аппакова Д.** Сараның башыннан үткәннәре: хикәяләр һәм пьеса /кереш сүз авт. Л. Ихсанова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 136 б.

**Аппакова Д.** Кечкенә Бануның тарихы: повесть, хикәяләр, әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 168 б.

**Аппакова Д.** Избранное / авт. вступ ст. С.Ибрагимова. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 320 с.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.1 /[төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Дәрҗия Аппакова. – Б. 42–43.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Дәрҗия Аппакова. – Б. 14–15.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Аппакова Дәрҗия Сәйфулла кызы. – Б.19–20.

**Ихсанова Л.** Дәрҗия Аппакова // Казан утлары. – 1978. – № 3. – Б. 176– 177.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Аппакова Дарджия Сейфулловна. – С. 31–33.

## 18 апрель/апреля



## Ибрагим НУРУЛЛИН
## Ибраһим НУРУЛЛИН

**1923–1975**

**100 лет со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Писатель, литературовед и критик Ибрагим Зиннятович Нуруллин родился 18 апреля 1923 года в селе Боровка нынешнего Мелекесского района Ульяновской области в семье учителя. Окончив восемь классов Мелекесской средней школы, в 1938 году приезжает в Казань и учится в меховом техникуме.

В октябре 1941 года добровольцем уходит в армию. Летом 1942 года направляется на Сталинградский фронт. В ноябре того же года в одном из боев за оборону города Астрахани И.Нуруллин тяжело ранен и лечится в госпитале, после чего увольняется с военной службы и возвращается в родное село. Проработав некоторое время учителем в сельской школе, И.Нуруллин в 1945 году вновь приезжает в Казань и поступает в университет на отделение татарской филологии. После окончания университета в 1950 году поступает в аспирантуру.

В 1953 году И. Нуруллин защищает кандидатскую диссертацию, посвящённую идейно-эстетическим воззрениям Г.Тукая. С этого времени его профессиональная деятельность связана с кафедрой татарской литературы Казанского государственного университета, где он сначала работает ассистентом, затем старшим преподавателем, доцентом. В 1967 году ученый защищает докторскую диссертацию на тему «Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе». В 1978–1990 годах И.Нуруллин работает в должности профессора-консультанта на кафедре русской и зарубежной литературы.

И.Нуруллин пришёл в литературу как прозаик-рассказчик. В 1944–1945 годах в журнале «Совет әдәбияты» («Советская литература», ныне «Казан утлары») были опубликованы его первые творческие опыты: «Ана тойгылары» («Ана күңеле»), «Рахматулла абзый», «Кунакта» («Район үзәгендә»). Затем он увлекается литературной критикой и научно-исследовательской работой. Особенно его интересует татарская литература начала XX века, в частности творчество Г. Тукая. Уже в начале 1950-х годов И.Нуруллин проявляет себя как литератор и публицист, опубликовав такие труды, как «Тукайның әдәби пародияләре» («Литературные пародии Тукая», 1948), «Тукай тәнкыйтендә типиклык мәсьәләләре» («Вопросы типичности в критике Тукая», 1953), «Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты» («Эстетика Тукая и русская литература», 1955), а также статьи, посвящённые творчеству Ф.Амирхана, Ш.Камала, отдельным проблемам истории татарской литературы, текущего литературного движения.

В 1960–1970 годы учёный издает ряд монографий, посвященных теоретическим вопросам методологии творчества и литературных направлений в татарской литературе, проблемам зарождения и развития критического реализма, публикует учебники и методические пособия по истории татарской литературы, теории литературы, литературоведению («XX йөз башы татар әдәбияты» («Та-

тарская литература начала XX века»), «Әдәбият теориясе» («Теория литературы» и др.).

Наряду с плодотворной работой в области литературоведения и критики И.Нуруллин создает и художественные произведения: рассказы для детей, юморно-сатирические, драматические произведения, циклы рассказов о Тукае на основе документов, связанных с жизнью и творчеством поэта.

В 1975 году И.Нуруллин завершает научно-литературное произведение «Габдулла Тукай». За эту книгу, изданную в серии «Жизнь замечательных людей», в 1982 году учёный был удостоен Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая.

В 1980-е годы учёный в серии «Жизнь замечательных людей» издаёт научно-популярную книгу о Фатихе Амирхане. В последние годы жизни писатель прилагает самоотверженные усилия по сохранению литературного наследия видного деятеля татарской литературы, культуры и национально-освободительного движения Гаяза Исхаки, активно продвигает его научное и художественное творчество через публикацию статей о нём. В 1992 году И.Нуруллину была присуждена литературная премия Союза писателей Татарстана имени Г.Исхаки.

Ибрагим Нуруллин скончался 1 июля 1975 года в Казани. Похоронен на Татарском кладбище в Ново-Татарской слободе.

Язучы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Ибраһим Зиннәтулла улы Нуруллин 1923 елның 18 апрелендә хәзерге Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс районы Парау авылында укытучы гаиләсендә туа. Мәләкәс урта мәктәбенең сигезенче сыйныфын тәмамлаганнан соң, 1938 елда Казанга килә һәм мех техникумында укый.

1941 елның октябрендә үз теләге белән армиягә китә. 1942 елның җәендә Сталинград фронтына җибәрелә. Шул елның ноябрендә Әстерхан шәһәрен саклау өчен барган сугышларның берсендә ул каты яраланып, госпитальдә дәвалана, аннары хәрби хезмәттән азат ителеп, туган авылына кайта. Берникадәр вакыт авыл мәктәбендә укытучы булып эшләгәч, И.Нуруллин, 1945 елда яңадан Казанга килеп, университетның татар филологиясе бүлегенә укырга керә. 1950 елда университетны тәмамлагач, аны аспирантурада укырга калдыралар.

1953 елда, Г.Тукайның идея-эстетик карашларын тикшерүгә багышланган гыйльми хезмәте нигезендә, ул кандидатлык диссертациясен яклый. Шул вакыттан алып И.Нуруллин озак еллар Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасында башта ассистент, соңга таба өлкән укытучы, доцент.

1967 елда ул «Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 1978–1990 елларда И.Нуруллин университетның рус һәм чит ил әдәбиятлары кафедрасында профессор-консультант хезмәтендә була.

И.Нуруллин әдәбият мәйданына прозаик-хикәяче буларак килеп керә. 1944–1945 елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында аның «Ана тойгылары» («Ана күңеле»), «Рәхмәтулла абзый», «Кунакта» («Район үзәгендә») исемле беренче иҗат тәҗрибәләре басылып чыга. Аннары ул әдәби тәнкыйть һәм фәнни-тикшеренү эшләре белән мавыгып китә. Аны бигрәк тә XX йөз башы татар әдәбияты, аерым алганда, Г.Тукай иҗаты кызыксындыра. Җентекле тикшеренүләр нәтиҗәсендә туган «Тукайның әдәби пародияләре» (1948), «Тукай тәнкыйтендә типиклык мәсьәләләре» (1953), «Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты» (1955) кебек хезмәтләре, шулай ук Ф.Әмирхан, Ш.Камал иҗатларына, татар әдәбияты тарихының, агымдагы әдәби хәрәкәтнең аерым проблемаларына багышланган мәкаләләре белән И.Нуруллин илленче еллар башында ук инде үзен әдәбиятчы-тәнкыйтьче итеп таныта.

1960–1970 елларда галим татар әдәбиятында иҗат методлары һәм әдәби юнәлешләр, критик реализмның туу һәм үсү мәсьәләләре турында теоретик гомумиләштерүләргә бай булган монографияләрен яза һәм татар әдәбияты тарихы, әдәбият теориясе, әдәбият белеме буенча берничә дәреслек һәм методик кулланма китабын бастырып чыгара («XX йөз башы татар әдәбияты», «Әдәбият теориясе» һ.б.) .

Әдәбият белеме һәм тәнкыйте өлкәсендә нәтиҗәле эшләү белән бергә, И.Нуруллин әдәби әсәрләр язуын да онытмый: балалар өчен хикәяләр, юмор-сатира, драма әсәрләре, Тукай тормышына һәм иҗатына бәйле документлар нигезендә шагыйрь турында хикәяләр циклы иҗат итә.

1975 елда И.Нуруллин фәнни-әдәби әсәрен – «Габдулла Тукай» исемле китабын язып тәмамлый. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә басылып чыккан бу китабы өчен әдип-галим 1982 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

1980 нче елларда галим Фатих Әмирхан турында да фәнни-әдәби китабын язып бастыра. Әдип татар әдәбияты, мәдәнияте һәм милли азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкиле Гаяз Исхакыйның исемен һәм әдәби мирасын халыкка кире кайтару юлында да фидакяр тырышлыклар күрсәтә, язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәкаләләрен бастыра. 1992 елда И.Нуруллинга Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләге бирелә.

Ибраһим Нуруллин 1995 елның 1 июлендә Казанда вафат була. Яңа Татар бистәсендәге татар зиратында җирләнә.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Нуруллин И. Габдулла Тукай.** – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 303 б.

**Нуруллин И.** Тормыш һәм сәнгать чынлыгы: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 192 б.

**Нуруллин И.** Фатих Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 279 б.

**Нуруллин И.З.** Моңлы саз чыңнары: Тукай турында документаль роман. – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 272 б.

**Нуруллин И.** Путь к зрелости: о зарождении и развитии критического реализма в татарской литературе. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. – 350 с.

**Нуруллин И.** Тукай / авториз. пер. с татар. Радия Фиша. – М.: Мол. гвардия, 1977. – 238 с. – (Жизнь замечательных людей).

**Нуруллин И.** Напевы мятежного саза: повесть о жизни и творчестве Габдуллы Тукая / перевод с татар. – М.: Детская литература, 1986. – 221 с.: ил.

**Нуруллин И.** Прометей из Ново-татарской слободы: документальная повесть / пер. с татар. Г.Нуруллиной. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 270 с.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.2 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Ибраһим Нуруллин. – Б. 223–225.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Ибраһим Нуруллин. – Б. 358–361.

**Нуруллина Р.** Томаннарга еллар күмелде…: истәлекләр. – Казан: Матбугат йорты, 2003. – 109 б.

**Ибраһим Нуруллин:** истәлекләр / төз. Р.Нуруллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 136 б.

**Харрасова Р.Ф.** Ибраһим Нуруллин – галим, тәнкыйтьче, прозаик. – Казан: [РИЦ], 2012. – 172 б.

**Хәкимов Ә.** «Тукай» // Казан утлары. – 1998. – № 4. – Б. 157–159.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Нуруллин Ибрагим Зинятович. – С. 328–329.

## 21 апреля/апрель



## Равиль ТУМАШЕВ
## Равил ТУМАШЕВ

**1923–2016**

**100 лет со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Режиссёр, педагог Равиль Рахимович Тумашев родился 21 апреля 1923 года в городе Семипалатинске в семье известных театральных деятелей Кашифы и Рахима Тумашевых. После рождения сына Равиля семья Тумашевых вернулась в Казань, где и прошло его детство. В период обучения Кашифы Тумашевой в ГИТИСе мальчик воспитывался в московском детском доме «Пионер-дом».

В 1941 году Р. Тумашев окончил среднюю школу в Казани. С началом Великой Отечественной войны был призван в Красную Армию и направлен

в Чкаловское зенитное училище. С августа 1942 года Р. Тумашев – младший лейтенант, офицер шифровальной спецсвязи штаба; выполняет служебные обязанности офицера-шифровальщика в самых различных ситуациях, участвует в обеспечении связи между частями и командованием в боевой операции на Курской дуге, в операциях по освобождению Украины, Польши и Чехословакии. В конце войны командирован в Войско Польское. На разных должностях прослужил до 1946 года.

Р.Тумашев награждён Орденом Красной Звезды, медалью «За боевые заслуги», наградой Польской Народной Республики «Серебряный крест за заслуги».

После демобилизации, в 1946–1951 годах, Р.Р.Тумашев учится в Государственном институте театрального искусства им. А.В.Луначарского (ГИТИС) на режиссёрском факультете. На сцене Татарского государственного академического театра ставит дипломный спектакль по драме М.Файзи «Галиябану».

В 1952–1962 годах Р. Тумашев работает режиссёром в Татарском государственном академическом театре имени Г. Камала, где ставит такие спектакли, как «Отелло» В.Шекспира (1953), «Анджело» В.Гюго (1954), «Легенда о любви» Н.Хикмета (1955), «На берегу реки Урал» М.Файзи (1958), «Наследники Рабурдена» Э.Золя (1959) и др.

В 1963–1985 годах Р.Р.Тумашев работает главным режиссёром Татарского республиканского передвижного театра (ныне – Татарский государственный театр драмы и комедии имени К.Тинчурина); является постановщиком более шестидесяти спектаклей: «Палата» С.Алёшина, «Забавный случай» К.Гольдони, «Мой бедный Марат» А.Н.Арбузова, «Мещане» М.Горького. Незабываемые постановки спектаклей «Молодые сердца Ф.Бурнаша, «Шамсикамар» М.Аблеева, «Ходжа Насретдин» Н.Исанбета продемонстрировали высокий профессионализм, художественный вкус и большой творческий потенциал Р.Р.Тумашева.

С 1964 года режиссер активно работает с молодыми татарскими драматургами, продвигая их пьесы на сцене татарского театра. Ставит пьесы «Кара күзле кызлар» («Черноглазые девушки», 1964), «Шомырт чәчәк атканда», («Когда цветёт черёмуха», 1968) А.Гилязова, «Нигез ташлары» («Фундамент», 1968), «Йөрәк янар өчен бирелгән» («Сердце должно гореть», 1970), «Уйланыр чак» («Пора раздумий», 1972) Т.Миннуллина, «Бөркетләр кыяга оялый» («Орлы гнездятся на скалах», 1970) И.Юзеева.

Спектакли «Судьбы, избранные нами» («Үзебез сайлаган язмыш», 1973) «Покаяние» («Ак тәүбә, кара тәүбә», 1976) по пьесам Т. Миннуллина, «Подсолнух» («Сары чәчәк ата көнбагыш»), «Соловушка с шёлковым шнурком» («Ефәк баулы былбыл кош», 1982) по пьесам А.Гилязова, «К нам прилетели соловьи» («Сандугачлар килгән безгә», 1974), «Вслед за дикими гусями» («Кыр казлары артыннан», 1976) по пьесам И.Юзеева явили собой события, ознаменовавшие коренное обновление репертуара татарского театра.

Под руководством Р. Тумашева была воспитана целая плеяда актёров. На протяжении многих лет Равиль Рахимович преподаёт режиссуру и актёрское мастерство в Казанском театральном училище и Казанском государственном институте культуры, руководит литературно-драматическим творчеством студентов.

Р. Тумашев – заслуженный деятель искусств Татарской АССР (1966), лауреат Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая (1976).

Р.Р.Тумашев скончался 2 января 2016 года.

Режиссёр, педагог Равил Рәхим улы Тумашев 1923 елның 21 апрелендә Семипалатинск шәһәрендә танылган театр эшлеклеләре Кәшифә һәм Рәхим Тумашевлар гаиләсендә туа. Уллары Равил тугач, Тумашевлар гаиләсе Казанга кайта. Аның балачагы Казанда һәм өлешчә, әнисе ГИТИСта уку сәбәпле, Мәскәүдәге балалар йортында үтә.

1941 елда Р.Тумашев Казанда урта мәктәпне тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башлану белән, аны Кызыл Армиягә алалар һәм Чкалов зенит училищесына җибәрәләр; 1942 елның август аеннан ул кече лейтенант – штабның махсус элемтәсен шифрлаучы була. Офицер-шифрлаучы вазыйфаларын төрле ситуацияләрдә үти, Курск дугасындагы хәрби бәрелештә, Украина, Польша

һәм Чехословакияне азат итү операцияләрендә частьлар һәм командованиеләр арасындагы элемтәне тәэмин итүдә катнаша. Сугыш ахырында ул Польшага командировкага җибәрелә, төрле вазифалар башкарып, 1946 елга кадәр хезмәт итә.

Р.Тумашев Кызыл Йолдыз ордены, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале, Польша Халык Республикасының «Казанышлар өчен көмеш хач» белән бүләкләнә.

Сугыштан демобилизацияләнеп кайткач, Р.Тумашев 1946–1951 елларда Мәскәүдә А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссёрлык факультетында укый. Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә М.Фәйзинең «Галиябану» драмасы буенча диплом спектакле куя.

1952–1962 елларда ул Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында режиссёр булып эшли: сәхнәгә У.Шекспирның «Отелло» (1953), В.Гюгоның «Анджело» (1954), Н.Хикмәтнең «Мәхәббәт хикәясе» (1955), М.Фәйзинең «Урал суы буенда» (1958), Э.Золяның «Рабурден варислары» (1959) һәм башка спектакльләр чыгара.

1963–1985 елларда Равил Тумашев Татарстан республика күчмә театрында (хәзер К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) баш режиссёр; алтмыштан артык әсәрне сәхнәгә куя. Тәүге спектакльләре: «Тынгысыз йөрәк» («Палата», С.Алёшин), «Көлкеле хәл» («Забавный случай», К.Гольдони), «Минем бичара Маратым» («Мой бедный Марат», А.Н.Арбузов), «Мещаннар» («Мещане», М.Горький). Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр», М. Әблиевнең «Шәмсекамәр», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» онытылмас спектакльләре, Р.Р.Тумашевның югары профессиональлеген, сәнгати зәвыгын һәм зур иҗади потенциалын күрсәтте.

1964 елдан Р.Тумашев яшь татар драматурглары белән актив эшли башлый, аларның пьесаларын татар театры сәхнәсенә чыгара. А.Гыйләҗевнең «Кара күзле кызлар» (1964), «Шомырт чәчәк атканда» (1968), Т.Миңнуллинның «Нигез ташлары» (1968), «Йөрәк янар өчен бирелгән» (1970), «Уйланыр чак», И.Юзеевның «Бөркетләр кыяга оялый» (1970) пьесаларын сәхнәләштерә. «Үзебез сайлаган язмыш», «Ак тәүбә, кара тәүбә» (Т.Миңнуллин пьесалары, 1973, 1976), «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев пьесалары, 1974, 1982), «Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан» (И.Юзеев пьесалары, 1974, 1976) спектакльләре татар театры репертуарын нигездән яңарткан әһәмиятле вакыйгалар буларак кабул ителәләр.

Бер үк вакытта, Равил Рәхим улы күп еллар дәвамында Казан театр училищесында һәм Казан дәүләт мәдәният институтында режиссура һәм актёрлык осталыгын укыта, студентларның әдәби-драматик иҗаты белән җитәкчелек итә.

1966 елда Р.Р.Тумашевка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. 1976 елда ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты була.

Равил Рәхим улы Тумашев 2016 елның 2 гыйнварында бакыйлыкка күчә.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:


**Дөнья драматургиясеннән үрнәкләр:** пьесалар / тәрҗ. һәм төз. Равил Тумашев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 507 б.

**Тумашев Р.** Үзе сайлаган язмыш: әң-мә / әңгәмәдәш Л. Хәбибуллина // Шәһри Казан. – 2013. – 4 апрель. – Б.7.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Тумашев Равил Рәхим улы. – Б. 492–493.

**Мөслимова Ф.** Үзе сайлаган язмыш // Сәхнә. – 2012. – № 10. – Б. 6–9.

**Бәйрәмова Г.** «Мин арый торган кеше түгел» // Казан утлары. – 2013. – № 7. – Б. 159–160.

**Акмал Н.** Иҗат мәйданнары тар иде... // Сәхнә. – 2022. – № 5. – Б. 34–35.

**Күңелнең сәҗдәгә киткән чагы** // Шәһри Казан. – 2010. – 20 май. – Б. 8.

**Тумашев А.** Жизнь в искусстве театра. Воспоминания об отце: [о Равиле Тумашеве] // Идель. – 2017. – № 5. – С. 6–11.

**Илялова И.** Театр имени Тинчурина. – Казань: Идел-Пресс, 2002. – 278 с.: фото. – О Р.Тумашеве. – С. 62–69.

## 17 июня/июнь



### Шамиль МУХАМЕДЬЯРОВ Шамил МӨХӘММӘДЬЯРОВ

**1923–2005**

**100 лет со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Видный советский и российский учёный, историк-тюрколог (специалист по средневековой истории тюркских народов) Шамиль Фатыхович Мухамедьяров родился 17 июня 1923 года в Казани в семье известного врача и государственного деятеля Ф.Г.Мухамедьярова.

После окончания школы, в 1942–1943 годах работает токарем на оборонном заводе. В 1943 году поступает в Казанский юридический институт, в 1946–1950 годах учится в аспирантуре. В 1951 году успешно защищает кандидатскую диссертацию на тему «Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства». В 1950–1952, 1955–1956 годах – научный сотрудник в Институте языка, литературы и истории Казанского филиала Академии наук СССР. С 1952 по 1955 год является учёным секретарём Института востоковедения АН СССР.

В 1955 году Ш.Ф.Мухамедьяров возвращается в Казань, преподает в Казанском государственном университете в должности доцента, а с 1959 года заведует кафедрой истории СССР.

В 1963–1970 годах Шамиль Фатыхович работает старшим научным сотрудником и руководителем группы Якутского филиала Сибирского отделения АН СССР.

В 1970–1996 годах Ш.Ф.Мухамедьяров работает в Москве в Центре истории народов России и межэтнических отношений Института истории АН СССР (с 1992 года – Институт российской истории РАН), в качестве автора и консультанта принимает участие в подготовке 2-го и 3-го изданий Большой Советской Энциклопедии, а также энциклопедии «Отечественная история». Работает профессором в Московском высшем духовном исламском колледже.

В разное время Ш.Ф.Мухамедьяров читает лекции по специальным историческим дисциплинам в Литературном институте (Москва), Московском, Чувашском, Восточном гуманитарном, Казанском и Якутском университетах, Казанском педагогическом университете, Московском высшем духовном исламском колледже, Татарском государственном гуманитарном институте.

Ш.Ф.Мухамедьяров был одним из самых деятельных российских тюркологов. В сферу его научных интересов входила история народов Поволжья, Приуралья и Сибири. Неоценим вклад учёного в историографию и источниковедение истории тюркских народов, изучение межэтнического и межконфессионального взаимодействия в Волго-Уральском регионе.

Ш.Ф. Мухамедьяров – автор более 170 научных работ по средневековой истории тюркских и финно-угорских народов Поволжья и Приуралья, истории Крыма и Якутии. Многие его работы увидели свет в солидных академических изданиях СССР и России, а также за рубежом – в Турции, Финляндии, Японии, Венгрии, Германии и других странах.

Ш.Ф. Мухамедьяров принял деятельное участие в возрождении Общества истории, археологии и этнографии при Казанском университете; был избран на должность его вице-председателя.

Ш.Ф.Мухамедьяров был членом Российского национального комитета тюркологов и Археографической комиссии РАН, членом Президиума, академик-секретарь и академик Международной тюркской академии. В 1968 году ученый был избран членом Постоянной Международной комиссии алтаистов PIAC (США). 9 января 1997 года избран членом-корреспондентом Российской академии естественных наук по отделению сословных и национальных традиций, а 29 декабря 1997 года – действительным членом РАЕН.

Долгое время Ш.Ф.Мухамедьяров являлся членом экспертного совета по истории Российского гуманитарного научного фонда и диссертационного совета Института этнологии и антропологии Российской Академии наук.

В 1993 году Ш.Ф.Мухамедьяров был удостоен почётного звания заслуженного деятеля науки Республики Татарстан. В разные годы награждён медалями, среди которых «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», «В память 850-летия Москвы» и др. В 75-летнем возрасте Шамиль Фатыхович совершил хадж.

Шамиль Фатыхович Мухамедьяров скончался 23 мая 2005 года в Москве.

Күренекле Совет һәм Россия галиме, тарихчы-тюрколог (төрки халыкларның урта гасыр тарихы буенча белгеч) Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяров 1923 елның 17 июнендә Казанда танылган табиб һәм дәүләт эшлеклесе Ф.Г.Мөхәммәдьяров гаиләсендә туа.

Мәктәпне тәмамлап, 1942–1943 елларда оборона заводында токарь булып эшли. 1943 елда Казан юридик институтына укырга керә, аны тәмамлагач, 1946–1950 елларда аспирантурада укый. 1951 елда «Казан ханлыгының социаль-икътисади һәм дәүләт төзелеше» темасына кандидатлык диссертациясен яклый. 1950–1952, 1955–1956 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр була. 1952–1955 елларда СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында гыйльми секретарь булып эшли.

1955 елда Ш.Ф.Мөхәммәдьяров Казанга кайта, Казан дәүләт университетында укыта, башта доцент, ә 1959 елдан СССР тарихы кафедрасы мөдире була.

1963–1970 елларда Шамил Фатих улы СССР Фәннәр академиясе Себер бүлегенең Якут филиалында өлкән фәнни хезмәткәр һәм группа җитәкчесе булып эшли.

1970–1996 елларда Ш.Ф.Мөхәммәдьяров Мәскәүдә, СССР ФА Тарих институтының (1992 елдан – Россия Фәннәр академиясенең Россия тарихы институты) Россия халыклары тарихы һәм милләтара мөнәсәбәтләр Үзәгендә эшли, автор һәм консультант буларак Зур совет энциклопедиясенең 2 һәм 3 басмаларын, шулай ук «Отечественная история» («Ватан тарихы») энциклопедиясен төзүдә катнаша. Аннары Мәскәү югары рухи ислам көллиятендә профессор булып эшли.

Төрле вакытта Ш.Ф.Мөхәммәдьяров Әдәбият институтында (Мәскәү), Мәскәү, Чуаш, Көнчыгыш гуманитар, Казан һәм Якут университетларында, Казан педагогика университетында, Мәскәү югары рухи ислам көллиятендә, Татар дәүләт гуманитар институтында тарих фәненең төрле махсус тармакларына караган лекцияләр укый.

Ш.Ф.Мөхәммәдъяров Россия тюркологларының иң активларыннан берсе була. Аның фәнни кызыксыну даирәсенә Идел буе, Урал һәм Себер халыклары тарихы керә. Галимнең төрки халыклар тарихы тарихын һәм чыганакларын өйрәнүгә, Идел-Урал төбәгендә этносара һәм конфессияара багланышларны тикшерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез.

Ш.Ф.Мөхәммәдьяров – Идел буе һәм Урал буе төрки һәм фин-угор халыкларының урта гасыр тарихы, Кырым һәм Якутия тарихы буенча 170 тән артык фәнни хезмәт авторы. Аның күп хезмәтләре СССР һәм Россиянең дәрәҗәле фәнни матбугат органнарында һәм нәшриятларында, шулай ук чит илләрдә – Төркия, Финляндия, Япония, Венгрия, Германия һәм башка илләрдәге зур академик басмаларда дөнья күрә.

Ш.Ф.Мөхәммәдьяров Казан университеты каршындагы Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте эшчәнлеген яңадан башлап җибәрүдә катнаша; бу җәмгыятьнең вице-рәисе итеп сайлана.

Ш.Ф.Мөхәммәдьяров – Россия тюркологлар милли комитеты һәм Россия Фәннәр академиясенең археография комиссиясе әгъзасы, Халыкара Төрки академиянең Президиум әгъзасы, академик-секретаре һәм академигы. 1968 елда ул алтайчыларның PIAK (АКШ) Даими Халыкара комиссиясе әгъзасы итеп сайлана. 1997 елның 9 гыйнварында Россия Табигать фәннәре академиясенең милек һәм милли традицияләр бүлеге әгъза-корреспонденты, ә 1997 елның 29

декабрендә – Россия Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. Озак вакыт ул Россия гуманитар фәнни фондының тарих буенча экспертлар советы әгъзасы һәм Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институтында диссертация советы әгъзасы була.

1993 елда Ш.Ф.Мөхәммәдьяров Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек була. Ул күп тапкыр медальләр белән бүләкләнә, алар арасында «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакяр хезмәт өчен» һәм «Мәскәүнең 850 еллыгы истәлегенә» һ. б. бар. 75 яшендә Шамил Фатих улы хаҗ кыла.

Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяров 2005 елның 23 маенда Мәскәүдә вафат була.

### Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Мөхәммәдяров Ш.** Казан ханлыгының тышкы сәүдәсе // Чын мирас. – 2012. – № 8–9. – Б. 61–75.

**Мухамедьяров Ш.Ф.** Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV – первая половина XVI вв.) /АН РТ, Ин-т истории им. Ш.Марджани. – Казань: Ихлас, 2012. – 275 с. + карты, ил.

**Мухамедьяров Ш.Ф.** «Казанское взятие»: взгляд из XXI века // Научный Татарстан. – 2012. – № 3. – С. 31–40.

**Мухамедьяров Ш.Ф.** Изучение в СССР основных этапов военно-политической истории тюркских народов Поволжья и Приуралья; Древнейшие этнические связи народов Поволжья с Западной Сибирью; На стыке континентов и цивилизаций // Культурные традиции Евразии: сб.науч.тр. / АН РТ [и др.]. – Казань: Фән, 2004. – С.461–481. – (Восток-Запад: Диалог культур Евразии: проблемы средневековой истории и археологии. Вып. 4 / под ред. А.А.Бурханова).

**Бәдретдинов Х.Ф.** Мең тамырлы нигез хакы // Зеленодольский регион: проблемы истории и культуры: тезисы и материалы Региональной научно-практической конференции «Историко-культурное наследие Зеленодольского региона и Татарстана в ракурсе преподавания истории и музейно-краеведческой работы в школе» (г. Зеленодольск, 24 октября 2003 года). – Казань: Gumanitarya, 2003. – С.234–250. – (Восток-Запад: диалог культур Евразии, Проблемы истории и археологии. Вып. 3 / под ред. А. А. Бурханова).

**Хамидуллин Б.Л.** История Казанского ханства в трудах отечественных историков (1920–1950-е гг.) // Научный Татарстан. – 2012. – № 3. – С. 92–113.

**Бурханов А.** От редактора: [о Ш.Ф. Мухамедьярове] // Культурные традиции Евразии: сб.науч.тр. / АН РТ [и др.]. – Казань: Фән, 2004. – С.8–11. – (Восток-Запад: Диалог культур Евразии: проблемы средневековой истории и археологии. Вып. 4 / под ред. А.А.Бурханова).

**Хамидуллин Б.Л.** По следам Михаила Худякова («Забытый» труд середины XX столетия по истории Казанского ханства) // Культурные традиции Евразии: сб.науч.тр. / АН РТ [и др.]. – Казань: Фән, 2004. – С.13–24. – (Восток-Запад: Диалог культур Евразии: проблемы средневековой истории и археологии. Вып. 4 / под ред. А.А.Бурханова).

## 23 августа/август



## Лябиба ИХСАНОВА
## Ләбибә ИХСАНОВА

### 1923–2010

### 100 лет со дня рождения
### тууына 100 ел

Детская писательница, переводчица, публицист Лябиба Фаизовна Ихсанова родилась 23 августа 1923 года в татарской деревне Нижние Шуни Вятскополянского района Кировской области в семье учителей. Закончив в 1941 году среднюю школу в посёлке Кукмор Татарской АССР, два года работает пионервожатой в семилетней школе

своей родной деревни и одновременно помощником бригадира в местном колхозе.

В 1943 году Лябиба Ихсанова приезжает в Казань и поступает на географический факультет Казанского университета. В студенческие годы начинает писать стихи, рассказы, близко общается со студентами только что открывшегося в университете отделения татарского языка и литературы, регулярно посещает их литературные кружки, где знакомится с писателями, проходит первую экспериментальную школу по обучению литературному мастерству.

После окончания университета в 1948 году Л.Ихсанова полностью посвящает себя литературному творчеству и журналистике. Трудовую деятельность начинает в Татарском радиокомитете в качестве сотрудника редакции детского вещания. Затем была главным редактором журнала «Пионер» (ныне «Ялкын»). В 1960–1967 годах работает редактором в редакции детско-юношеской литературы Татарского книжного издательства, затем ответственным секретарем в журнале «Казан утлары» («Огни Казани»).

Первая книга писательницы «Көмеш елга» («Серебряная река») издаётся в 1948 году. Её литературное творчество обогащается новыми произведениями: повести «Нияз», «Нияз мәктәптә» («Нияз в школе»), «Тал бөгелә» («Ива гнётся»), «Робинзоннар лагеренда» («В лагере робинзонов»), «Саралан малайлары» («Мальчики Саралана»), «Ана көндәлеге» («Дневник матери»), «Җир астында җиде көн» («Семь дней под землёй»), «Якты уйлар» («Светлые мечты»), «Космонавтлар урамы» («Улица космонавтов»), «Авылдашлар» («Односельчане»), «Наил һәм Фаил» («Наиль и Фаиль»), рассказы «Сөйләнмәгән сер» («Невысказанная тайна»), «Тау чәчәге» («Горный цветок») и др. Из произведений конца шестидесятых и начала семидесятых годов наибольшего внимания заслуживают ее повести «Очкын» («Искра», 1969) и «Гөлләр кояшка карый» («Цветы смотрят на солнце», 1972).

Л.Ихсанова – автор более трёх десятков книг. Отдельные её произведения переведены на русский, украинский, эстонский, чувашский, башкирский языки. В первые годы своего творческого пути она переводит на татарский язык повести русского писателя Л. Кассиля «Улица младшего сына» (1953) и чувашского писателя А.Талвира «На Буинском тракте» (1958).

Л.Ихсанова регулярно выступает в периодической печати с публицистическими статьями по различным социальным вопросам, с критическими статьями по детской литературе, пишет воспоминания о своей жизни.

За заслуги в области татарской детской литературы и журналистики Л.Ихсановой в 1972 году было присвоено почётное звание заслуженного работника культуры Татарской АССР, в 1983 году – заслуженного работника культуры РСФСР. В 1996 году Л. Ихсанова удостоена литературной премии А.Алиша Союза писателей Татарстана.

Лябиба Фаизовна Ихсанова умерла 27 июля 2010 года.

Балалар язучысы, тәрҗемәче, публицист Ләбибә Фәез кызы Ихсанова 1923 елның 23 августында Киров өлкәсенең Вятские Поляны (Нократ аланы) районы Түбән Шөн авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1941 елда Татарстан АССРның Кукмара районы үзәгендә урта мәктәпне тәмамлагач, туган авылының җидееллык мәктәбендә ике ел әйдәман (вожатый) һәм күмәк хуҗалык бригадасында бригадир ярдәмчесе булып эшли.

1943 елда Ләбибә Казанга килеп, Казан дәүләт университетының география факультетына укырга керә. Студент елларында каләм тибрәтә башлый: шигырьләр, хикәяләр яза, университетта яңа ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары белән якыннан аралашып, аларның әдәбият түгәрәкләренә даими йөри, шунда язучылар белән таныша, әдәби осталыкка өйрәнү юлында беренче тәҗрибә мәктәбен уза.

1948 елда университетны тәмамлагач, Л.Ихсанова үзен тулысынча әдәби иҗат эшенә һәм журналистикага багышлый. Үз хезмәт юлын ул Татарстан радиокомитетында балалар өчен тапшырулар

редакциясе хезмәткәре буларак башлый. Аннары «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналының баш мөхәррире була. 1960–1967 еллар арасында Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли. Соңыннан «Казан утлары» журналында җаваплы секретарь эшен башкара.

Язучының «Көмеш елга» исемле беренче китабы 1948 елда басалып чыга. Аның әдәби иҗат хәзинәсе яңадан-яңа әсәрләр белән байый бара: «Нияз», «Нияз мәктәптә», «Тал бөгелә», «Робинзоннар лагеренда», «Саралан малайлары», «Ана көндәлеге», «Җир астында җиде көн», «Якты уйлар», «Космонавтлар урамы», «Авылдашлар», «Наил һәм Фаил» дигән повестьлар, «Сөйләнмәгән сер», «Тау чәчәге» һәм башка шундый хикәяләр иҗат итә. Алтмышынчы еллар ахыры һәм җитмешенче еллар дәвамында язган әсәрләре арасында авторның «Очкын» (1969) һәм «Гөлләр кояшка карый» (1972) исемле повестьлары аеруча игътибарга лаеклы.

Л.Ихсанова – өч дистәдән артык китап авторы. Аның аерым әсәрләре рус, украин, эстон, чуаш, башкорт телләренә тәрҗемә ителә. Ул үзе дә иҗат юлының беренче чорларында тәрҗемә эше белән шөгыльләнә: рус язучысы Л.Кассильнең «Улица младшего сына» («Кече улның урамы», 1953), чуаш язучысы А.Талвирның «На буинском тракте» («Буа юлында», 1958) исемле повестьлары татарча дөнья күрә.

Л.Ихсанова тиз үзгәрүчән тормыш-көнкүрешнең төрле мәсьәләләренә багышланган публицистик чыгышлары, балалар әдәбиятына кагылышлы тәнкыйть мәкаләләре һәм бай тормыш тәҗрибәсенә нигезләнгән истәлек язмалары белән көндәлек матбугатта даими катнаша.

Татар балалар әдәбиятын үстерүдәге һәм журналистика өлкәсендәге хезмәтләре өчен Л.Ихсановага 1972 елда Татарстан АССРның һәм 1983 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә. 1996 елда ул Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премиясенә лаек була.

Ләбибә Ихсанова 2010 елның 26 июлендә вафат була.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Ихсанова Л.** Наил, Фаил һәм башкалар: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 416 б.

**Ихсанова Л.** Тузганак: повесть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 257 б.

**Ихсанова Л.** Кемгә сөйлим серләремне?: хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 320 б.

**Ихсанова Л.** Шомырт чәчәкләре ак кына: хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 2003. (Латин графикасында.)

**Ихсанова Л.** В лагере робинзонов: повесть /пер. с татар. А.Некрасова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 128 с.

**Ихсанова Л.** Акробат: повесть: пер. с татар. – М.: Дет. лит., 1987. – 63 с.

**Ихсанова Л.** На душе неспокойно: повести : пер. с татар. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. – 200 с.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.1 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Ләбибә Ихсанова. – Б. 633–635.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Ләбибә Ихсанова. – Б. 215–217.

**Шәрәфи Г.** Ихласлылык // Казан утлары. – 1983. – № 8. – Б. 137–141.

**Хисамов Н.** Бәрәкәтле чишмәләр: әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 150 б. – Бәрәкәтле чишмәләр. – Б. 67–75.

**Гыймадиев А.** Балачакның тугры илчесе // Казан утлары. – 2003. – № 8. – Б. 132–134.

**Яхина Р.** Көчле мәктәп үткән кешеләр // Шәһри Казан. – 2003. – 22 авг.

**Юнысова А.** Берсе ай, берсе кояш! // Ватаным Татарстан. – 2003. – 30 авг.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Ихсанова Лябиба Фаизовна. – С. 215–216.

**Ахмадуллин Ш.** Лябиба Ихсанова //Дет. лит. – 1976. – № 4. – С. 12–15.

## 1 октября/октябрь



### Файзи БИККИНИН
### Фәйзи БИККИНИН

**1898–1968**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Исполнитель на народных инструментах (гармонь, скрипка) Файзи (Файзрахман) Бикмухаметович Биккинин родился 1 октября 1898 года в городе Казани. С 1915 года начинает выступать на эстраде (в том числе в составе инструментального ансамбля татарской драматической труппы «Сайяр») как скрипач и исполнитель на концертных гармониках.

В 1918 году вместе с С.Сайдашевым участвует в организации театрально-музыкальной студии в г. Буинске. В 1930–1937 годах – солист Татарского радио, в 1937–1963 годах – солист Татарской государственной филармонии.

Файзи Биккинин виртуозно владеет навыками игры на гармониках различных конструкций. В его репертуар входят старинные татарские народные напевы («Аллюки», «Зиляйлюк», «Кара урман», «Уел», «Тафтиляу»), произведения татарских композиторов, мелодии песен и танцев разных народов.

Музыкант гастролирует в Уфе, Ташкенте, Алма-Ате и др. В период Великой Отечественной войны выступает в составе концертных бригад в Прибалтике, Польше, Германии.

Файзи Биккинин стоял у истоков и внёс значительный вклад в развитие самобытного татарского концертного исполнительства на традиционных музыкальных инструментах. В 1963 году ему присвоено почётное звание заслуженного артиста ТАССР.

Ф.Биккинин умер 29 марта 1968 года в Казани.

Музыка уен коралларында (гармун, скрипка) уйнау остасы Фәйзи (Фәйзерахман) Бикмөхәммәт улы Биккинин 1898 елның 1 октябрендә Казан шәһәрендә туа. 1915 елдан эстрадада (шул исәптән татар драма труппасы «Сәйяр»нең инструменталь ансамблендә) скрипкачы һәм концерт гармуннарында уйнаучы буларак чыгышлар ясый.

1918 елда С.Сәйдәшев белән бергә Буа шәһәрендә театр-музыка студиясен оештыруда катнаша. 1930–1937 елларда Татарстан радиосында, 1937–1963 елларда – Татар дәүләт филармониясе солисты булып эшли.

